**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28 .10. 2024** **№ 54-6**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының «Тәтеш муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында»2017 елның 16 маендагы 22-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, "махсус сакланылучы табигый территорияләр турында" 14.03.1995 № 33-ФЗ Федераль Законы нигезләмәләренә таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының 16.05.2017 ел, № 22-4 карары белән расланган Тәтеш муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә җирләрне кертү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тәтеш муниципаль районы территориясендәге җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә (алга таба - махсус сакланылучы территорияләр җирләре) җирләр керә::

1) махсус сакланылучы табигать территорияләре;
2) дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар;
3) табигатьне саклау билгеләнеше;
4) рекреацион билгеләнештәге;
5) тарихи-мәдәни билгеләнештәге;
6) аеруча кыйммәтле җирләр.»;

1.2. 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гражданнар, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар җирле үзидарә органнарына махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану чараларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә хокуклы. Әлеге чараларны гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары гражданнарның, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның тәкъдимнәрен исәпкә ала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Советының җирдән файдалану, аграр һәм табигатьне саклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Башлыгы вазыйфаларын башкаручы** **Е.Г. Курков**